# Рафис Корбан иҗаты.


ТР Арча районы Субаш-Аты башлангыч мәктәбе укытучысы Нәгыймова Роза Рәгать кызы

2012-2013



**Рафис Корбан(1957ел 1гыйнвар)**

Биектау районы Кече Битаман авылында туа. Башлангыч белемне туган авылында ала. Урта мәктәпне тәмамлагач Казанга укырга китә.



**Булачак шагыйрь әти - әнисе белән**



Бу хәйләкәр малайлар  арасында да Рафис бар.



Башлангыч мәктәптә 9 яшьләрендә чакта ук каләм тирбәтә башлый. 1971елда беренче шигыре «Таң көтеп» «Яшь ленинчы» (хәзерге «Сабантуй») газетасында басылып чыга.



Роберт абый Миңнуллин Рафис Корбанның яңа язган шигырьләрен укый.



1987-”Буран кайда йоклый?”-беренче шигырьләр китабы.
1991-”Сөзгәк болыт.”
1992-”Капкорсак”
1993-”Капкорсак һәм Бавырсак.” исемле шигъри җыентыклары нәшер ителә.

“Капкорсак” китабы өчен автор 1993елда Ш. Маннур исемендәге әдәби бүләккә лаек була.



Рафис физкультура белән дә дус.



**Дуслар-каләмдәшләр.**

Х.Әюпов, Р.Корбан, Р.Кукушкин, С.Шәмси (сулдан уңга.)



Рафис абыйның шигырьләрен генә түгел, үзен дә бик ярата балалар.

Рафис  Корбанның  балалар драматургиясен баету юнәлешендәге  иҗади эшчәнлеге дә игътибарга лаек. Аның «Куркуын җиңгән  куян», «Керпе малае дуслар эзли» һәм башка пьесалары сәхнәләштерелде.

- Рафис Корбан җыр текстлары авторы буларак та билгеле. Аның күп кенә  шигырьләренә профессиональ һәм  үзешчән композиторлар  тарафыннан  көйләр язылган.


# “Түз инде”

Куянымның бер колагын
Белмим ,кайсы өзгәндер.
Бик тә авырткандыр инде.
Белмим, ничек түзгәндер?
Түзүен дә түзгәндер ул,
Инде менә моннан соң
Мин сөйләгән шигырьләрне
Ничек итеп тыңлар соң?
Әни эштән кайтсын инде,
Түз куяным, түз генә,
Әниемнән яңа колак
Тектерермен үзеңә!




# “ Тыныч булыгыз.”

Су керүе рәхәт тә соң
Җәйге кызу челләдә!
Йөзә белмәсәм дә тормыйм
Ялынып беркемгә дә.
Тирәнгә дә кереп китәм,
Тормыйм әле сакланып.
Чөнки йөзәм крокодилның
Мин үзенә атланып.
Крокодил дигәч тә, алай
Уйламагыз әллә ни.
Чын түгел ул, аны бары
Өреп кабартты әни.



# “Ташбака”

Ташбаканы кызганам  мин.
Ярдәм итәр идем дә...
Үз өен һаман күтәреп
Йөртә мескен иңендә.
Бер явызы алып китә
Күрмәсен тагын диеп,
Шулай күтәреп йөртәдер
Инде, мөгаен, өен.
Соң, ул ташны кемгә кирәк
Диеп беләдер инде?
Һәркемгә өй кадерле шул,
Шуңа күрәдер инде.
Ташбаканың  хәлен белдем.
Башкалар да аңлыйдыр-
Өен күтәреп барганга
Кызу йөри алмыйдыр.



# Тест

- **1.Рафис Корбан ничәнче елда туган?**
- м)1957елда б) 1960елда с)1961елда
- **2. Рафис Корбанның беренче шигыре кайчан һәм кайда басыла?**
- о)1971 елда “Яшь ленинчы” д)1970елда”Салават күпере” в)1957елда “Сабыйга”
- **3.Р.Корбанның беренче басылган шигырьләр китабының исеме.**
- о)”Сөзгәк болыт” л)”Буран кайда йоклый?” н)”Җиде төстә кунакта”
- **4.1993елда кайсы китабы өчен автор Ш.Маннур исемендәге бүләккә лаек була?**
- а) ”Буран кайда йоклый?” т)” Сөзгәк болыт” о)”Капкорсак”
- **5.”Түзәм инде”шигырендә куянның колагы нишләгән?**
- д)өзелгән щ)туңган в)өшегән
- **6.”Тыныч булыгыз” шигырендә малай нишли?**
- а)ашый е)су керә в)укый
- **7. Шигырьдә Ташбака нәрсә күтәреп йөри?**
  ц) өен б)китап п)үлән.

# Тест җаваплары

1. ***М*** *-* 1957 елда.
2. ***О*** *-* 1971елда “Яшь ленинчы”.
3. ***Л*** *-* ”Буран кайда йоклый?”.
4. ***О*** *-* “Капкорсак”.
5. ***Д*** *-* Өзелгән.
6. ***Е*** *-* Су керә.
7. ***Ц*** *-* Өен.

Бу материаллар «Салават күпере» журналыннан алынды.

2003ел №7.